КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 октябрь г.Казань № 943

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендәтөбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләре һәм курортлар турында» 2015 ел, 5 июнь, 418 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләре һәм курортлар турында« 2015 ел, 5 июнь, 418 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 560 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның бишенче абзацына «, шифаханә-курорт оешмаларын да кертеп,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Территорияләрне дәвалау-савыктыру урыннары һәм төбәк әһәмиятендәге курортлар дип тану тәртибендә:

12 пунктта «төбәк әһәмиятендәге курортлар» сүзләреннән соң «, шул исәптән санатор-курорт оешмаларын да кертеп» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымтада «(Ф.И.Ә.и.)» сүзләрен «(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Территорияләрне дәвалау-савыктыру урыннары һәм төбәк әһәмиятендәге курортлар дип тану тәртибендә:

12 пунктта «җирле әһәмияттәге курортлар» сүзләреннән соң «, шул исәптән санатор-курорт оешмаларын да кертеп» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымтада «(Ф.И.Ә.и.)» сүзләрен «(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Дәвалау-савыктыру урыннары һәм төбәк әһәмиятендәге курортлар реестрын алып бару тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк әһәмиятендәге дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортларның, шул исәптән шифаханә-курорт оешмаларының реестрын алып бару тәртибе»;

1 пунктта «төбәк әһәмиятендәге курортлар» сүзләреннән соң «, шифаханә-курорт оешмаларын да кертеп» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Реестрда, санатор-курорт оешмалары турында белешмәләрне дә кертеп, региональ әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлары турында белешмәләр бар.»;

3 пунктта «әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8 - 35 пунктчалар өстәргә:

8)шифаханә-курорт оешмасы төре (шифаханә, балалар шифаханәсе, ата-аналары белән балалар өчен шифаханә, шифаханә-профилакторий, бальнеология дәваханәсе һ. б.);

9) шифаханә-курорт оешмасының урнашу урыны;

10) җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), телефон, факс, электрон почта адресы;

11) оештыру-хокукый формасы;

12) милек формасы (милекче, хуҗасы, кулланучылар күрсәтелгән);

13) ведомство буйсынуы;

14) юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык нигезендә дәүләт теркәү номеры;

15) ОКПО коды;

16) салым түләүченең идентификациояләү номеры (ИНН);

17) ОКВЭД кодлары;

18) ОКУН буенча хезмәт күрсәтү төре коды;

19) җир кишәрлегеннән файдалануга хокук билгели торган документ;

20) җир кишәрлегенең мәйданы (га);

21) шифаханә-курорт ярдәмен гамәлгә ашырганда башкарыла торган эшләр (хезмәтләр күрсәтүләр) өлешендә медицина эшчәнлегенә лицензия булу (лицензия номеры, гамәлдә булу срогы, лицензияләүче орган);

22) медицина эшчәнлегенә лицензиягә кушымталар нигезендә оешманың медицина белгечлеге (профиль);

23) юнәлеш (өлкәннәр өчен, балалар өчен, ата-аналар белән балалар өчен);

24) эшчәнлек чоры (ел әйләнәсе; сезонлы - айлар), заездлар саны;

25) сыйдырышлыгы (уртача еллык ятаклар саны; максималь җәелү аенда ятаклар саны; сменага килүчеләр саны);

26) юллама буенча дәвалану озынлыгы (көн);

27) урнаштыру (корпусларның мәйданы, аларның катлылыгы, сыйдырышлыгы);

28) номер фонды (номерлар саны, алар арасыннан люкс классы һәм уңайлыкларсыз, аларны җиһазлау);

29) тукрануны оештыру;

30) файдаланыла торган табигый дәвалау ресурслары Исемлеге (шифаханә-курорт оешмасы балансында табигый дәвалау ресурслары булганда аларның характеристикасы 3 - 5 пунктларга туры килә);

31) табигый дәвалау ресурсларын куллану объектлары исемлеге;

32) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр (шифаханә-курорт оешмасы балансында табигый дәвалау ресурслары булганда);

33) билгеләнгән тәртиптә теркәлгән кулланыла торган медицина технологияләре исемлеге;

34) медицина кадрлары:

34.1) штаттагы һәм биләгән вазыйфалар санын, физик затлар санын, шулардан – белгеч сертификаты булганнарын күрсәтеп,  табиб вазыйфалары исемлеге;

34.2) штаттагы һәм биләгән вазыйфалар санын, физик затлар санын, алардан – белгеч сертификаты булганнарын күрсәтеп,  урта медицина персоналы вазыйфалары исемлеге;

35) оешма территориясендә инфраструктура объектлары исемлеге.»;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымтаны төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин